*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА
**БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**а**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Оясыз сандугач сайрамый*. (Мәкаль)
   а) 3
   ә) 4
   б) 5
   в) 6

2. Җөмләдәге ачык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Куркак аулакта батыр була*. (Мәкаль)
   а) 3
   ә) 4
   б) 5
   в) 8

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***сакал сыйпап калу***
   а) алдану
   ә) саубуллашу
   б) изге теләкләр теләп калу
   в) борчылу

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) теләк
   ә) хыял
   б) өмет
   в) гомер

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кием(салым)
   ә) җир(су)
   б) эт(шомырты)
   в) яр(канат)

6. Билгеләү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) кемдер
ә) кайда
б) һәркем
в) берни

7. Затланышлы фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) исем фигыль
ә) боерык фигыль
б) хәл фигыль
в) сыйфат фигыль

8. Сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) җиләк
ә) баллы җиләк
б) җиләк-җимеш
в) кура җиләге

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Куркакның йодрыгы* ***кесәсендә***. (Мәкаль)

а) ия
ә) хәбәр
б) урын хәле
в) тәмамлык

10. Мәкальләр арасыннан кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең.
ә) Иренгәннең иренен эт ялаган.
б) Ир мактаныр, корал эшләр.
в) Иренмәгән иртәгәге эшен бүген бетергән.

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

[и] авазының калын пары __________. Татар телендә ачык һәм _____________ иҗекләр бар. Бер иҗекле сүзгә басым тамгасы _____________. Билгеле бер грамматик формада гына омоним булып килгән сүзләр _____________ дип атала. Парлы сүзләр _____________ аша языла. *Ул* зат һәм _____________ алмашлыгы була ала. Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан _____________ куела. Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә _____________ җөмлә дип атала.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**

*көче, эшкә, кулыңнан, бар, кырык, килмәгән, кешенең, тотынма, коралда*

______________________________________________________________

______________________________________________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Верблюд – одно из самых выносливых животных. Несколько недель он может идти под палящим солнцем и не пить. При этом он ещё и груз несёт. Поэтому верблюд для человека в пустыне незаменим. Его называют “кораблём пустыни”.

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

УРМАН

Тезелеп үскән төрле зур агачлар,
Үзе матур, үзе куркыныч;
**Яшел хәтфә кебек яфраклары**
**Кайвакытта тора тып-тыныч.**

Тып-тын торган ошбу серле урман,
Төрле матур кошлар оясы;
Матур кошларына табигатьнең
Бүләк итеп биргән дөньясы.

*(Мәҗит Гафури)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)** ____________________________________

2.2. Искергән сүзне һәм аның кайсы сүз төркеменә караганлыгын языгыз. **(2 балл)** ____________________________________________________

2.3. Шигырьдә кулланылган синонимнарны языгыз. **(1 балл)**

______________________________________________________________

2.4. Тартым белән төрләнгән исемнәрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: җөмлә кисәкләрен һәм аларның төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

3. ***“Серле урман”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**